**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«20» 08 2024 ел Яр Чаллы шәһәре № 3712

2024 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплексы программаны раслау турында

Тукай муниципаль районы территориясенең тиешле санитар, эстетик торышын тәэмин итү һәм аны алга таба төзекләндерү максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2024 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплексы программа»ны расларга.
2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

# 2024 ЕЛГА ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЭКОЛОГИК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА КОМПЛЕКСЛЫ ПРОГРАММА

Яр Чаллы шәһәре
2024 ел

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td>Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплекслы программа</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td>Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td>- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- авыл җирлекләре башкарма комитетлары;<br>- авыл җирлекләре башлыклары;<br>- коммуналь комплекс оешмалары</td></tr>
<tr><td>Программаның максатлары һәм бурычлары</td><td>Программаның төп максатлары:<br>- районның тотрыклы социаль-икътисадый үсешен су ресурслары белән гарантияле тәэмин итү;<br>- халыкның экологик уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүче су объектларын саклау һәм торгызу;<br>- халыкны һәм икътисад объектларын су басудан һәм суларның башка тискәре йогынтысыннан саклауны тәэмин итү;<br>- халыкның экологик уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүче су объектларын торгызу;<br>- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;<br>- Тукай муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру.<br>Бу максатларга ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү;<br>- су ресурсларының локаль дефицитларын бетерү;<br>- су объектларына тискәре антропоген йогынтыны киметү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру вакыты</td><td>2024</td></tr>
<tr><td>Финанслау күләме</td><td>Программаны финанслау күләме 3 503,0 мең сум тәшкил итә</td></tr>
<tr><td>Финанслау чыганаклары</td><td>Федераль бюджет, ТР бюджеты, район бюджеты, авыл җирлекләре, инвесторлар бюджетлары средстволары (мең сум)
<table>
<tr><td>Финан-слау чыга-нак-лары</td><td>РФ бюд-жеты</td><td>ТР бюд-жеты</td><td>Район бюджеты/ авыл җирлекләре бюджетлары средство-лары</td><td>Пред-приятие сред-ство-лары</td><td>Инвес-тиция-ләр</td></tr>
<tr><td>2024</td><td colspan="2">-</td><td>18 533,15</td><td></td><td></td></tr>
</table>
Эшләрнең бәясе, барлыгы 18 533,15 мең сум.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик зыянны булдырмый калу 3 503,0 мең сум күләмендә фаразлана.<br>Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру тиешле дәрәҗәдә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмау;<br>- район халкы өчен уңайлы тормыш кирлеген булдыру;<br>- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү;<br>- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирә мохиткә сак караш формалаштыру; экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру. |

## 1. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**Максатлар:**

- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;
- Тукай муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.

**Бурычлар:**

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә, тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән сәяси, икътисадый, технологик, хокукый, социаль, медицина, санитария-гигиена, эпидемиягә каршы чараларны исәпкә алып, дәүләт сәясәтен тормышка ашыру;

– җир, су, урман, минераль һәм башка ресурслардан файдалануның экологик нигезләнгән методларын кертеп, тотрыклы үсешкә юнәлтелгән табигатьтән комплекслы файдалануны гамәлгә кертү;

– хуҗалык эшчәнлегеннән тискәре экологик нәтиҗәләрне булдырмау, булачак экологик нәтиҗәләрне исәпкә алу;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итү системасының функциональ нәтиҗәлелеген тәэмин итү;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә карарлар әзерләүдә, фикер алышуда, кабул итүдә һәм тормышка ашыруда катнашуны тәэмин итү.

## 2. Тукай муниципаль районында экологик куркынычсызлыкны, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануны һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча эшчәнлекне анализлау

Рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү проекты Территорияне биологик объектлар өчен куркынычсыз булган нормаль хәлгә кайтару чараларын күздә тота.

Рекультивация юнәлешләре:

• биогазны зарарсызландыру;
• агынты суларны чистарту;
• каты калдыкларны дезактивацияләү.

Рекультивация ике этаптан тора:

1. Техник: участокны секторлар буенча планлаштыру, грунтны күчерү, мелиоратив, гидротехник һәм башка эш төрләре.

2. Биологик: туфракны сәламәтләндерүгә юнәлдерелгән торгызу чараларын (агротехник һәм фитомелиоратив) үз эченә ала.

Чүплекләрне рекультивацияләү максатлары:

Бу процесс калдыкларны саклау өчен файдаланылган җирләрне торгызу өчен кирәк. Ул территорияне чүп-чардан чистартуны, туфрак һәм суның пычрануын бетерүне, шулай ук табигый үсемлекләрне торгызуны үз эченә ала. Чүплекләрдә грунтка һәм грунт суларына үтеп керә ала торган куркыныч химик матдәләр туплана, атмосфераны пычрата, төрле авырулар барлыкка килүгә этрә. Рекультивация бу куркынычларны бетерергә, туфракны табигый халәткә кайтарырга мөмкинлек бирә. Калдыкларны саклауның элекке территориясендә үсемлекләр һәм флораны торгызу биотөрлелекне саклап калырга һәм әйләнә-тирә мохиттә яшәү сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә.

Чүплекләрне рекультивацияләү этаплары:

Процесс берничә этапны үз эченә ала.

Беренче этап территорияне чүп-чардан чистарту. Бу махсус техника ярдәмендә башкарылырга мөмкин, ул территориядән чүп-чарны нәтиҗәле җыештырырга мөмкинлек бирә. Аннан соң туфрак һәм суның пычрануын бетерү кирәк. Бу физик-химик чистарту, биологик чистарту, дренаж системаларын куллану кебек төрле ысуллар ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Пычрануларны бетергәннән соң, табигый үсемлекләрне торгызу кирәк. Бу агач, куак һәм үләнчел үсемлекләрне утырту юлы белән башкарылырга мөмкин. Чүплек территориясендә үсемлекләр үрчү биотөрлелекне саклап калырга, әйләнә-тирә мохиттә яшәү сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә.

Чүплекләрне рекультивацияләү шартларының берсе - экологик чиста материаллар куллану. Бу таш, туфрак һәм үлән кебек табигый материалларны куллану белән эшләнергә мөмкин. Экологик чиста материаллар куллану әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметергә ярдәм итә.

Чүплекләрне рекультивацияләү-әйләнә-тирә мохитне һәм кешеләрнең сәламәтлеген саклауда мөһим адым. Ул җирне табигый хәлгә кайтарырга, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы өчен уңай шартлар тудырырга ярдәм итә. Бу калдыкларны утильләштерү проблемасын чишүдә мөһим элемент.

## 3. Төп юнәлешләр һәм чаралар.

Яшелләндерү – үсемлек утыртмаларын булдыру һәм куллану белән бәйле эшләр җыелмасы; киңрәк мәгънәдә – әйләнә-тирә мохитнең экологик торышын яхшыртуга һәм территорияне төзекләндерүгә юнәлтелгән эшләр.

Яшелләндерү – шәһәрләрдә сәламәтләндерүнең төп чарасы һәм яшел киңлек булдыру, мөһим экологик әһәмияткә ия. Агачлар һәм куаклар оптималь микроклиматик шартлар тудыралар, һаваның газ составын көйлиләр, торак территорияләрне шәһәр тавышыннан саклыйлар, микроорганизмнарны юкка чыгаручы  һәм үсешен тоткарлаучы фитонцидлар бүлеп чыгаралар, шулай ук эстетик матурлык чыганагы булып торалар.

Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары – калдыкларны урнаштыру өчен каралмаган территорияләр. Калдыкларны шәһәр һәм авыл җирлекләре янындагы территорияләрдә, урман-парк, курорт, дәвалау-савыктыру, ял итү зоналарында, хайваннар миграциясе юлларында, уылдык чәчү урыннары янында һәм әйләнә-тирә мохит, табигый экологик системалар һәм кеше сәламәтлеге өчен куркыныч тудырырга мөмкин булган башка урыннарда урнаштыру тыела (мәсәлән, сусаклагычларның ярларында һәм вакытлыча су басу зоналарында, эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау территорияләрендә); шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән радиоактив калдыкларны, өске һәм җир асты су объектларына, су җыю мәйданнарына, җир асты һәм туфракка ташлау тыела. Моннан тыш, торак пунктлар, су саклау

зоналары чикләрендә, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла торган җир асты су объектларының су җыю мәйданнарында калдыкларны күмү тыела

Җир кишәрлеге милекчесе каты коммуналь калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерүне мөстәкыйль тәэмин итәргә яки каты коммуналь калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру өчен ачыкланган урынны бетерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә региональ оператор белән килешү төзергә тиеш.

## 4. Программаны финанс белән тәэмин итү.

2024 елга программаны тормышка ашыру өчен ихтияж 18 533,15 мең сум тәшкил итә.

## 5. Көтелгән соңгы нәтиҗәләр.

- әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмый калу;
- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.
- экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру;
- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирәлеккә сак караш формалаштыру;
- район халкы өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру.

1 кушымта

**2024 елда Тукай муниципаль районы
бюджет акчалары хисабына финанслауга каралган
табигатьне саклау чаралары исемлеге**

мең сум

| № | Чара коды * | Табигатьне саклау чарасының исеме | Чараның тасвирламасы, егәрлек | Гамәлгә ашыру срогы | Бәясе агымдагы бәяләрдә | Финанслау чыганаклары буенча 2024 ел лимиты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Карар № 1370, 02.08.2022 НВОС, штрафлар, дәгъвалардан керемнәр күләменнән | НДПИ кереме күләмендә | Барлыгы |
| 1. | 1.03. | "Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү, Кече Шилнә авыл җирлеге, Тукай муниципаль районы | 16:39:102402:4424 кадастр номерлы җир кишәрлегендә (Татарстан Республикасы)" (ГРОНВОСка кертелгән) | 2024 | 8 131,00 | 8 131,00 | 0,00 | 8 131,00 |
| 2. | 7.01. | Теләнче-Тамак авылындагы кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү, Теләнче-Тамак авыл җирлеге, Тукай муниципаль районы | 16:39:201001:29 кадастр номерлы, 3200 кв. м мәйданлы җир кишәрлегендә кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү, Теләнче-Тамак авылы | 2024 | 370,00 | 0,00 | 370,00 | 370,00 |
| 3 | 7.01. | Яңа Байлар авылында кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү, Күзкәй авыл җирлеге, Тукай муниципаль районы | Яңа Байлар авылында 5500 кв. м. мәйданлы кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү, координаталары 55.773155 52.772502 | 2024 | 370,00 | 0,00 | 370,00 | 370,00 |
| 4 | 7.01. | Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә иске кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү | Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә 16:39:081101:7 кадастр номерлы 10 000 кв. м мәйданлы җир кишәрлегендә иске кыргый карьерны рекультивацияләүгә проект-смета документациясен эшләү, координаталары 55.455238 52.474885 | 2024 | 370,00 | 0,00 | 370,00 | 370,00 |
| 5 | 10.02. | Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү | Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә 16:39:122601:333 кадастр номерлы 10 000 кв. м мәйданлы җир кишәрлегендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү | 2024 | 1 000,00 | 0,00 | 1 000,00 | 1 000,00 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | 8.02. | Тукай муниципаль районы Татарстан совх. пос. Князево авыл җирлеге территориясендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү | Татарстан совх. пос. Князево авыл җирлеге территориясендә 16:39:030103:16 кадастр номерлы 2 259 кв.м мәйданлы җир кишәрлегендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү (I этап) | 2024 | 1 943,00 | 0,00 | 1 943,00 | 1 943,00 |
| | | **Барлыгы 2024 ел** | | | | **8 131,00** | **4 053,00** | **12 184,00** |
| 2023 елда кулланылмаган калдыклар хисабына табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| 7 | 1.03. | "Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү, Кече Шилнә авыл җирлеге, Тукай муниципаль районы | 16:39:102402:4424 кадастр номерлы җир кишәрлегендә (Татарстан Республикасы)" (ГРОНВОСка кертелгән) | 2024 | 6 349,15 | 6 349,15 | 0,00 | 6 349,15 |
| | | **Барлыгы 2023 ел** | | | | **6 349,15** | **0,00** | **6 349,15** |
| | | **Барлыгы** | **х** | **х** | **х** | **14 480,15** | **4 053,00** | **18 533,15** |